МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 126/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«14» 08 2015

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында**

2003 елның 12 маендагы “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә **боерык бирәм:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.
2. Регламент һәм контрольлек бүлегенә елына ике тапкыр, яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 нче көненә кадәр гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ (алга таба – анализ) ясарга.
3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү секторына анализның Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының рәсми сайтында яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 нче көненнән дә соңга калмыйча урнаштырылуын тәэмин итәргә.
4. Юридик бүлеккә (Латыйпова Э.Ю.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.
5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ РЕГЛАМЕНТА И КОНТРОЛЯ №1

КОПИЯ ВЕРНА
Оригинал документа хранится в отделе регламента и контроля Министерства строительства, архитектуры и ЖКХ РТ

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалык
министрлыгының
2015 елның "14" 08
№126/о боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип 2003 елның 12 маендагы "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү максатында эшләнде һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында (алга таба – Министрлык) гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Министрлыкның регламент һәм контрольлек бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан электрон документ әйләнеше белешмәләре һәм әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә тапшырыла торган мәгълүмат нигезендә башкарыла.

3. Министрның, министрның беренче урынбасарларының, министр урынбасарларының, эшләр белән идарә итүченең (алга таба – Министрлык җитәкчелеге, гражданнарны шәхсән кабул итү буенча вәкаләт бирелгән затлар) шәхсән кабул итүе барышында ирешкән мәгълүматлар турында мәгълүмат Бүлеккә гражданнарны Министрлык җитәкчелегенә шәхсән кабул ителүгә теркәүче белгечләр тарафыннан тапшырыла.

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат Бүлеккә җаваплы хезмәткәрләр тарафыннан яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр тапшырыла.

5. Анализ үткәргәндә килгән, бер адрестан икенче адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ әйләнеше рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхсән кабул итү барышында кабул ителгән гражданнарның саны, гражданнарны шәхсән кабул итүгә вәкаләт бирелгән затлар һәм урынга чыгып шәхсән кабул итү турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәсендә кабул ителгән чаралар турындагы мәгълүмат, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка төрле актлар (булган очракта) турындагы мәгълүмат өйрәнелә.

6. Бүлек белгече 2 пунктта күрсәтелгән, шулай ук әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә ирешкән мәгълүматларны кергән көненнән алып ике эш көне

дәвамында гомумиләштерә һәм анализлый һәм килештерү өчен анализны министрга җибәрә.

7. Мөрәҗәгатьләрнең анализы массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү секторына Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру өчен җибәрелә. Анализ Министрлыкның рәсми сайтында яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче аеның 15 нче көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

8. Министрлыкта гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр анализы Министрлыкның рәсми сайтындагы (http://minstroy.tatarstan.ru/) ирекле файдалану өчен ачык мәгълүмат булып санала.

---